СОВЕТ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН
Ул. Чехова, д.18, с. Верхний Услон, 422570

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ СОВЕТЫ
Чехов ур., 18 нче йорт, Югары ослан авылы, 422570

Тел.: (84379) 2-13-38, факс: (84379) 2-18-39, E-mail: sovet.uslon@tatar.ru, verhniy-uslon.tatarstan.ru

РЕШЕНИЕ | КАРАР

30.10.2024 с. Верхний Услон № 52-673

## «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проекты хакында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарәне оештыруның гомуми принциплары турында» Федераль законның 44 статьясы һәм «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 7ст., Югары Ослан муниципаль районы Уставының 15, 106-108 статьялары нигезендә, Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы карар итте:

1. Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы һәм Югары Ослан муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан тәкъдим ителгән «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проектын беренче укылышта кабул итәргә һәм, тәкъдимнәрне, төзәтмәләрне һәм искәрмәләрне исәпкә алып, аның өстендә эшләүне дәвам итәргә (1 нче кушымта).

2. Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү буенча тәкъдимнәрне кабул итү, исәпкә алу һәм карау буенча киләсе составтагы эшче төркем төзергә:

- Никитина Людмила Николаевна-эшче төркем рәисе, Югары Ослан муниципаль районы Советы Аппараты җитәкчесе;
- Пичугина Надежда Валерьевна - эшче төркем секретаре, Югары Ослан муниципаль районы Советының оештыру-хокукый һәм кадрлар эше бүлеге начальнигы;

Эшче төркем әгъзалары:

- Колесова Елена Евгеньевна-Югары Ослан муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы рәисе;
- Хурматуллина Лилия Илфар кызы-Югары Ослан муниципаль районы Контроль–хисап палатасы рәисе;
- Бурдин Виктор Михайлович-Югары Ослан муниципаль районы Килди авыл җирлеге башлыгы;

3. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Советының карары проектына карата гражданнар тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибен расларга (2нче Кушымта).

4. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы

Советының карары проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибен расларга (3нче кушымта).

5. «ТР Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проекты буенча халык алдында тыңлауларны 2024нче елның 19нчы ноябре көнне 10.00 сәгатьтә Югары Ослан муниципаль районы Советының утырышлар залында: Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 йорт адресы буенча уздырырга.

6. Эшче төркемгә Югары Ослан муниципаль районында яшәүчеләрнең тәкъдимнәрен гомумиләштерергә һәм аларны Югары Ослан муниципаль районы Советына карауга кертергә.

7. Әлеге карарны Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында, шулай ук Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

8. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Югары Ослан муниципаль районы Советының законлылык, хокук тәртибе һәм регламент буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2024 елның 30 октябреннән № 52-673 карарына 1 номерлы кушымта

Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр

Уставның 6 статьясындагы 1 пунктының 28 пунктчасында «муниципаль район территориясендә җирле әһәмияттәге дәвалау-савыктыру урыннарын һәм курортларын саклауны булдыру, үстерү һәм тәэмин итү, шулай ук» сүзләрен төшереп калдырырга;

1.2. Уставның 8 статьясын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«8 статья. Муниципальара хезмәттәшлек.

1. Югары Ослан муниципаль районында муниципальара хезмәттәшлек федераль законнар һәм Татарстан Республикасы законнары нигезендә гамәлгә ашырыла»;

1.3. Уставның 35 статьясындагы 1 пунктына түбәндәге эчтәлекле 10.1 пунктча өстәргә:

«10.1) аның чит ил агенты статусын алуы»;

1.4. Уставның 40 статьясындагы 1 пунктын түбәндәге эчтәлекле 14 пунктча өстәргә:

«14. аның чит ил агенты статусын алуы»;

1.5. Уставның 41 статьясындагы 2 пунктына түбәндәге эчтәлекле 6 һәм 7 пунктчалар өстәргә:

«6). аның чит ил агенты статусын алуы;

7) җирле үзидарә органнары эшчәнлеге нәтиҗәлелеген бәяләү өчен күрсәткечләргә системалы рәвештә түбәнәю».

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2024 елның 30 октябреннән № 52-673 карарына
2 номерлы кушымта

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» муниципаль район Советы карары проектына гражданнарның тәкъдимнәрен исәпкә алу тәртибе

1. «Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында» Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проектына тәкъдимнәр 2024 елның 11 ноябренә кадәр язма рәвештә Ф.И. А.и. һәм авторның яшәү урыны турында белешмәләр белән кертелә. Тәкъдимнәр түбәндәге адрес буенча: 422570, ТР, Югары Ослан районы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 йорт, Югары Ослан муниципаль районы Советы, эш төркеме секретаре Пичугина Н.В. Татарстан Республикасының хокукый мәгълүматның рәсми порталында, Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында шимбә һәм якшәмбедән кала һәр көн саен 8.00 сәгатьтән 16.00 сәгатькә кадәр кабул ителә.

Белешмәләр өчен телефон: 8 (84379) 2-18-36.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин

Югары Ослан муниципаль районы Советының 2024 елның 30 октябреннән № 52-673 карарына
3 номерлы кушымта

«Татарстан Республикасы Югары Ослан муниципаль районы Уставына үзгәрешләр һәм өстәмәләр кертү турында»Югары Ослан муниципаль районы Советы карары проекты буенча фикер алышуда гражданнарның катнашу тәртибе

1. Ачык тыңлауларда катнашу өчен гаризалар түбәндәге адрес буенча: 422570, Татарстан Республикасы, Югары Ослан муниципаль районы, Югары Ослан авылы, Чехов урамы, 18 йорт, Югары Ослан муниципаль районы Советына Пичугина Н.В. шәхсән яки почта аша (конвертта«Устав турында фикер алышу» дигән тамга белән) кабул ителә.

2. Үз тәкъдимнәрен дәлилләү өчен гавами тыңлауларда, ТР Югары Ослан муниципаль районы Советына язма гаризалар җибәргән район халкы катнаша.

3. Ачык тыңлауларда халык алдында чыгыш ясау хокукыннан башка районның барлык кызыксынган кешеләре катнаша ала.

4. Катнашучыларны теркәү гавами тыңлаулар башланганчы 30 минут кала башлана.

5. Чыгыш хокукы белән гавами тыңлауларда катнашучылар гариза бирү вакытына бәйле рәвештә чиратлылык тәртибендә үз тәкъдимнәрен аргументацияләү өчен чакырыла.

6. Ачык тыңлауларда катнашучыларның чыгышлары 5 минуттан да артмаска тиеш.

Ачык тыңлауларда катнашучылар чыгыш ясаганнан соң чыгыш ясаучыларга рәислек итүче рөхсәте белән сораулар бирергә хокуклы.

8. Гавами тыңлауларда катнашучылар гавами тыңлаулар барышына тыкшынырга, аларны туктатырга һәм аларны үткәрүгә комачауларга хокуклы түгел.

9. Ачык тыңлауларда катнашучылар тарафыннан уздыру тәртибе бозылган очракта, рәислек итүче аларны утырыш залыннан чыгаруны таләп итәргә хокуклы.

Совет Рәисе,
Югары Ослан муниципаль районы Башлыгы Е.А. Варакин